ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2020 Казан ш. № 490-160/тп-2020

«Мамадыш су каналы» ачык акционерлык җәмгыятенең үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен 2021 елга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу кагыйдәләрен раслау һәм кайбер Россия Федерациясе Хөкүмәте актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 29 июлендәге 644 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мөрәҗәгать итүчеләрнең су белән тәэмин итүнең һәм (яки) ташландык суларны агызуның үзәкләштерелгән системаларына тоташтырган (технологик ялгаган) өчен индивидуаль тәртиптә түләү билгеләнә торган объектларының тоташтырыла (ялгана) торган йөкләнеш зурлыгын билгеләү турында» 2017 елның 22 апрелендәге 239 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шушы карар кушымтасына туры китереп, «Мамадыш су каналы» ачык акционерлык җәмгыятенең үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик тоташтыру) өчен тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2021 елның 1 гыйнварыннан 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
16.12.2020 № 490-160/тп-2020
карарына кушымта

«Мамадыш су каналы» ачык акционерлык җәмгыятенең үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик тоташтыру) өчен тарифлар

| Т/с | Күрсәткеч атамасы | Үлчәү берәмлеге | Тоташуга тарифлар (НДС исәбеннән башка) |
|---|---|---|---|
| 1. | Тоташтырыла торган йөкләнешкә тарифның база ставкасы | тәүлегенә мең сум/куб метр | - |
| 2. | Челтәрләр озынлыгына тарифның база ставкасы | мең сум/чм | 2 809,67 |
| 3. | Челтәрләрнең диаметрына карап, тариф дифференциацияләү коэффициенты: | | |
| 3.1. | диаметры 40 мм һәм азрак | – | 0,63 |
| 3.2. | диаметры 40 мм югарырак, 70 мм кадәр | - | 0,76 |
| 3.3. | диаметры 70 мм югарырак, 100 мм кадәр | - | 0,76 |
| 3.4. | диаметры 100 мм югарырак, 150 мм кадәр | - | - |
| 3.5. | диаметры 150 мм югарырак, 200 мм кадәр | - | - |
| 3.6. | диаметры 200 мм югарырак, 250 мм кадәр | - | - |
| 3.7. | диаметры 250 мм һәм аннан да югары | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге